КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 59

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 июль, 703 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы; 2022 ел, 18 ноябрь, 1232 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында»

2022 ел, 30 ноябрь, 1271 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга грантлар бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның өченче абзацында «10 нчы» сүзен «бишенче» сүзенә алмаштырырга;

2.4 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин